# КАРАР
## Татарстан РеспубликасыАзнакаймуниципаль районы
## Әгерҗе авыл җирлеге Советы

Әгерҗе авылы № 131-63 «15» март 2019ел

Татарстан Республикасы Азнакай
муниципаль районы «Әгерҗе» авыл
җирлегенең 14.06.2018 ел. № 102-45
карары белән расланган, Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
«Әгерҗе» авыл җирлегендә гражданнарның
мөрәҗәгатьләрен карау һәм муниципаль берәмлектә
гражданнарны шәхси кабул итүне тәэмин итү
буенча Нигезләмәгә үзгәреш кертү турында
( 17.10.2018 № 111-53 карар редакциясендә)

Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» Федераль законның 22 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктының үз көчен югалтуын тану турында» 2018 елның 27 декабрендәге 528-ФЗ номерлыФедераль закон нигезендә миграция өлкәсендә һәм эчке эшләр өлкәсендә дәүләт идарәсен үзгәртеп коруга бәйле рәвештә»

Әгерҗе авыл җирлеге Советы **карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Әгерҗе» авыл җирлегенең 14.06.2018 ел № 102-45 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Әгерҗе» авыл җирлегендә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм муниципаль берәмлектә гражданнарны шәхси кабул итүне тәэмин итү буенча Нигезләмәгә (17.10.2018 № 111-53 карар редакциясендә) 1.7 пунктының икенче абзацындагы "миграция өлкәсендә хокук кулану функцияләрен гамәлгә ашыра торган башкарма хакимиятнең федераль органы территориаль органы" сүзләрен «Эчке эшләр өлкәсендә башкарма хакимиятнең федераль органы территориаль органы»сүзләренә алмаштырырга.
2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo. tatarstan.ru.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис: Н.Н.Хасанов